РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 31 » 08 2023 г. №1326

Гражданнар кеременең һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. “2023 елның II кварталына Ютазы муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында” 2023 елның 19 апрелендәге 448 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Карары нигезендә, гражданнар кеременең максималь күләмен исәпләү өчен, 2023 елга Ютазы районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен - 40 571 сум күләмендә расларга.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь бәясен расларга. (1нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасарына гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән керемнең максималь күләмен файдаланырга.

Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___»________2023 ел №____
Карарына
кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләме**
**һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе**

| Гаилә әгъзалары саны | Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе | Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме |
|---|---|---|
| 1 | 730278 | 14482,72 |
| 2 | 1460556 | 14483,29 |
| 3 | 2190834 | 14483,47 |
| 4 | 2921112 | 14483,57 |
| 5 | 3651390 | 14483,62 |
| 6 | 4381668 | 14483,66 |
| 7 | 5111946 | 14483,69 |
| 8 | 5842224 | 14483,71 |
| 9 | 6572502 | 14483,72 |
| 10 | 7302780 | 14483,73 |